**Автор публикации: Насибуллина Ильмира Ильдаровна, воспитатель**

**МБДОУ "Детский сад комбинированного вида №12 "Росинка"**

**г. Азнакаево, Республика Татарстан**

**Название работы: "Авторская разработка (сказка)"**

**Тема: “Тылсымлы гөл”**

**Әкият.**

**“Тылсымлы гөл”.**

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер бик матур кыз.Аның әбисе белән бабасыннан тыш беркеме , дә булмаган.Хәер , юк-юк! Тагын якын дусты булган әле аның.Тәрәзә төбендә үсеп утырган бик матур гөл.

Кызның исеме Мәликә булган.Кыз гөлне бик яраткан, аның белән сокланган.Гөлгә җылы сулар сибә торган булган, узенең серләрен аңа сөйләгән.Гөл дә аны аңлаган төсле, яфракчыкларын селкеткән.

Шулай бер көнне, кызның әбисе белән бабасы, атны җигеп урманга, утын алып кайтырга китәләр.Әбисе Мәликәгә әйтеп калдыра:

-Кызым- йолдызым, бер кайда да чыгып китмә, өйдә генә тор.Безнең кайтуга, тәмле күмәчләр пешереп куй,- ди.

Мәликә өйдә кала.Әбиләре киткәч, камыр куя. Камыр өлгергәч, күмәчләр пешерә.Күмәчләре бик уңа, йомры булып, кабарып пешә.Тирә янга аларның хуш исләре тарала.Шулай күмәчләр пешереп, кыз төн җиткәнен дә сизми кала.Мәликә кайгыра башлый:

- Нигә кайтмыйлар икән минем әбием белән бабам?! Караңгыга калдылар, ич!
- Кыз мыштым гына еларга керешә.Шул вакыт, аңа кемдер:
- Чү дустым ,елама!,-ди.

Мәликә аптырап кала...Ул бит өйдә берүзе, беркемдә юк янында! Кыз як-ягына карый.Күзе тәрәзә төбендәге гөлгә төшә. Гөле бит аның терегә әйләнгән!!!Аның күзләре дә бар.авызы да бар. Гөл Мәликәгә карап елмаеп тора иде. Кыз аптыраште кала, нинди могҗиза!!!

- Исәнме дустым! Менә безнең танышыр вакыт та җитте! Мин синең ярткан гөлең. Мин бит сие һәрвакыт тыңлый идем,синең серләреңне дә беләм. Син миңа җылы сулар сипкәндә, мин назаланып тора  идем.
- Исәнме гөлкәем! Син мине аптыраштa калдырдың! Ничек син терегә әйләндең, бу бит могҗиза!
- Мин бит тылсымлы гөл. Син хәзер авыр хәлдә калдың, сиңа булышырга кирәк. Шуңа күрә, мин сиңа үземнем серемне ачырга булдым.

Кыз моңсланып калды, исенә әбисе белән бабасы теште.

- Нишлим соң, гөлкәем?! Әбием  белән бабам кайтмады, адаштылар микән?!
- Мәликә, син бер дә борчылма! Мин сиңа үземнем бер яфракчыгымны бирәм.Ул сиңа юл күрсәтер, караңгы урманда юлыңны яктыртып барыр.

Гөл Мәликәгә ал төстәге яфракчыгын бирә һәм кыз юлга чыга. Ал яфракчык ялтыр-йолтыр янып бара кызга юл күрсәтеп.

Урманда караңгы, агач шәүләләре әллә ниләр булып күренәләр, кыштыр-кыштыр нидер шыгырдап  та ала. Мәликә курыкмаска тырышып бара, яфракчык артыннан калмый. Тиздән ул тавыш ишетә:

- Коткарыгыз! Без аста!

Кыз тизрәк бара башлый һәм аның каршында бер чыкыр барлыкка килә. Тавышлар да шуннан чыга икән!

Мәликә чыкырга иелеп караса- әбисе дә, бабасы да шунда! Кыз сөенә, әби-бабай сөенә! Мәликә аларны берүзе чыгара алмый һәм ул кире авылга йөгерә. Авылдан ул  тирә- юндәге  ир –егетләрне булышырга алып килә.Шулар ярдәмендә, алар  әби- бабайны чыкырдан алып чыгалар. Әби белән бабай сөйләве буенча, алар кемдер ясаган тозакка ялгыш тешеп киткәннәр. Әлдә ярый Мәликә  аларны тапкан! Кем белә, бәлки төнлә аларны аю да ашап бетергңн булыр иде?!

 Шулай итеп, алар бергәләп  өйләренә кайталар. Кызлары пешергән камырлар белән, тәмләп чәйләр эчәләр. Әби белән бабай йокларга яткач, Мәликә гөле янына килеп:

- Гөлкәем, син йоклыйсыңмы?!

Гөл күзләрен ачып җибәрә:

- Юк дустым!
- Сиңа зур рәхмәтләремне әйтәсем килә!!! Рәхмәт, гөлкәем!!!Син миңа шундый нык ярдәм иттең, минем иң якын кешеләремне табып коткарырга булыштың! Мин моны мәңге онытмыйм! Син минем иң якын дустым булып каласың! Гөлкәем, син чын дус, син үзеңнең яфракчыгыңны да җәлләмәдең миңа!Рәхмәт!
- Сау- сәламәт бул! Син миңа җылы сулар сипсәң, биремне йомшартсаң, кояш нурларына чыгарып куйсаң- миңа шул җитә!
- Әлбәттә, мин боларның барысын да эшләргә тырышырмын! Вәгъдә бирәм!

Шулай итеп, безнең Мәликә, әбисе, бабасы һәм яраткан гөле белән матур, тату итеп яшәүләрен дәвам иткәннәр.

Насибуллина Ильмира.